# ФИГЫЛЬ

# Фигыль турында гомуми төшенчә

## Билгеләмә

**Предметның эшен, хәрәкәтен, хәлен, торышын белдерә торган сүзләр фигыль дип атала.**

## фигыль төрләнешләре:

1) **барлык һәм юклык белән төрләнә;**
2) **заман белән төрләнә;**
3) **наклонение белән төрләнә (боерык, теләк, шарт фигыльләр);**
4) **юнәлеш белән төрләнә;**
5) **зат-сан белән төрләнә.**

# Фигыльнең барлык-юклык белән төрләнеше

Барлык фигыль барлык-юклык белән төрләнә ала. Фигыльнең юклык формасы –ма/-мә кушымчалары белән ясала. Барлыкның махсус кушымчасы юк. Юклык кушымчасы фигыльнең нигезенә ялгана: бар-ма, кил-мә, сана-ма, эшлә-мә.

# Фигыльнең зат-сан белән төрләнеше

## Билгеләмә

**Эш, хәл, хәрәкәтне башкаручы затка ишарә итә торган кушымчалар зат кушымчалары дип атала.**

**I зат эшне сөйләүче башкарганын күрсәтә: кайтам, бирдем, укыганмын, сөйләрмен, язачакмын. I зат кушымчалары эшне сөйләүче (мин) үтәгәнне аңлаталар.**

**II зат эшне тыңлаучы башкарганын күрсәтә: кайтасың, киттең, алгансың, күтәрсең, үсәчәксең. II зат кушымчалары эшне тыңлаучы (син) үтәгәнне белдерәләр.**

**I I I зат эшне сөйләүчедән һәм тыңлаучыдан читтәге зат яки предмет башкарганын күрсәтә: кайта, керде, күргән, санар, җырлаячак. III зат кушымчалары булмаса да, эшнең өченче зат (ул) тарафыннан үтәлгәне аңлашылып тора.**

# Зат кушымчаларының төрләре:

**тулы төр**

| | берлек | күплек |
|---|---|---|
| I зат | -мын/-мен | -быз/-без |
| II зат | -сың/сең | -сыз/-сез |
| III зат | __ | -лар/ләр |

**кыска төр**

| | берлек | күплек |
|---|---|---|
| I зат | -м | -к |
| II зат | -ң | -гыз/-гез |
| III зат | __ | -лар/ләр |

# Хикәя фигыль
## Билгеләмә

**Эш, хәл, хәрәкәтнең булу-булмавын хикәяләү, хәбәр итү рәвешендә белдерелгән фигыль формалары хикәя фигыль дип атала.**

**Хикәя фигыльнең өч заманы бар:**
**хәзерге заман, үткән заман, киләчәк заманнар. Аларның тугыз формасы бар:**
**хәзерге заман ;**
**үткән заман -**
**билгеле (категорик)үткән заман;**
**билгеле (нәтиҗәле) үткән заман;**
**тәмамланмаган үткән заман;**
**күптән үткән заман;**
**кабатлаулы үткән заман;**
**киләчәк заман -**
**билгеле киләчәк заман;**
**билгесез киләчәк заман.**
**Хикәя фигыль барлык/юклык, зат-сан белән төрләнә.**

## Хикәя фигыль җөмләдә хәбәр булып килә.

Җәй көне. Эссе һавада мин суда коенам,

Чәчрәтәм, уйныйм, чумам, башым белән суны сөзәм.

(Г. Тукай. “Су анасы”)

# Киләчәк заман хикәя фигыль

## Киләчәк заман хикәя фигыльнең мәгънәсе:

**Киләчәк заман хикәя фигыль сөйләүче сөйләп торган вакыттан соң булган эш-хәлне белдерә.**

**Ул өч төрле була:**

**1) билгеле киләчәк заман;**
**2) билгесез киләчәк үткән заман;**
**3) киләчәк үткән заман;**

***1) Бирелгән фигыльләрне зат-сан белән барлыкта-юклыкта билгеле киләчәк заманда төрләндерегез.***

**яз**

| | берлек | күплек |
|---|---|---|
| **I зат** | **/** | **/** |
| **II зат** | **/** | **/** |
| **III зат** | **/** | **/** |

**яз**

| | берлек | күплек |
|---|---|---|
| I зат | язачакмын / язмаячакмын | язачакбыз / язмаячакбыз |
| II зат | язачаксың / язмаячаксыз | язачаксыз / язмаячаксыз |
| III зат | язачак / язмаячаклар | язачаклар / язмаячаклар |

***2) Бирелгән фигыльләрне зат-сан белән барлыкта-юклыкта билгесез киләчәк заманда төрләндерегез.***

| | **үс** | |
|---|---|---|
| | **берлек** | **күплек** |
| **I зат** | **/** | **/** |
| **II зат** | **/** | **/** |
| **III зат** | **/** | **/** |

# үс

| | берлек | күплек |
|---|---|---|
| I зат | үсәрмен / үсмәмен | үсәрбез / үсмәбез |
| II зат | үсәрсең / үсмәссең | үсәрсез / үсмәссез |
| III зат | үсәр / үсмәс | үсәрләр / үсмәсләр |

*Киләчәк заман фигыльләрен табыгыз. Билгеле киләчәк заманнан билгесез киләчәк заманны ясагыз.*

**«Мин кая басканымны белмим. Бер көндә әллә ничаклы үсәкән кебек булдым: уенмыни?! Минем колыным бар.Ул айгыр! Төсле алмачуарга әйләнәчәк! Тирә-якта дан тоткан ике агасы кебек чабышкы булачак!»**



# Хәзерге заман хикәя фигыль

## Хәзерге заман хикәя фигыльнең мәгънәләре:

1) җөмләдә хәзерге заман хикәя фигыль сөйләүче сөйләп торган чактагы эш, хәл, хәрәкәтне белдерә;

Мин язам, шунда күрәм:
Лампам эчендә май кими. (Г. Тукай)

2) даими яки гадәт буларак кабатлана торган эш, хәл, хәрәкәтне белдерә;

Идел Каспий диңгезенә коя.

3) якын киләчәктә булуы ышанычлы эшне аңлата;

Мин быел Төркиягә барам.

4) сөйләмне җанландыру өчен, үткән заман мәгънәсендә кулланыла.

1941 нче елда Бөек Ватан сугышы башлана.

*3) Бирелгән фигыльләрне зат-сан белән барлыкта-юклыкта хәзерге заманда төрләндерегез.*

**укы**

| | берлек | күплек |
|---|---|---|
| I зат | / | / |
| II зат | / | / |
| III зат | / | / |

# укы

| | берлек | күплек |
|---|---|---|
| I зат | укыйм / укымыйм | укыйбыз / укымыйбыз |
| II зат | укыйсың / укымыйсың | укыйбыз / укымыйбыз |
| III зат | укый / укымый | укыйлар / укымыйлар |

*Хәзерге заман фигыльләрен табыгыз. Барлык формасыннан юклык формасын ясагыз.*

**“Бүген бөтен авылның асты өскә килә. Әллә ничә йөзләп егетләр, ат менеп чыкканнар да, яшь киленле йортларга кереп, сөлге җыеп йөриләр. Малайлар, кайсы атта, кайсы җәяү өйдән-өйгә йомырка сорарга чыкканнар. Аларга яшелле-кызыллы буяуга буяп әзерләп куйганнар. Хатын-кызлар бертуктаусыз кайный: киенәләр, ясаналар, буяналар, тырт-мырт өйдән-өйгә йөгерәләр.»**



# Үткән заман хикәя фигыль

## Үткән заман хикәя фигыльнең мәгънәсе:

**Үткән заман хикәя фигыль сөйләүче сөйләп торган вакыттан элек булган эш-хәлне белдерә.**

**Ул берничә төрле була:**
**1) билгеле (категорик) үткән заман;**
**2) билгесез (нәтиҗәле) үткән заман;**
**3) тәмамланмаган үткән заман;**
**4) күптән үткән заман;**
**5) кабатлаулы үткән заман.**

***4) Бирелгән фигыльләрне зат-сан белән барлыкта-юклыкта билгеле үткән заманда төрләндерегез.***

**кара**

| | **берлек** | **күплек** |
|---|---|---|
| **I зат** | **/** | **/** |
| **II зат** | **/** | **/** |
| **III зат** | **/** | **/** |

## кара

| | берлек | күплек |
|---|---|---|
| I зат | карадым / карамадым | карадык / карамадык |
| II зат | карадың / карамадың | карадыыз / карамадыгыз |
| III зат | карады / карамады | карадылар / карамадылар |

***5) Бирелгән фигыльләрне зат-сан белән барлыкта-юклыкта билгесез үткән заманда төрләндерегез.***

**әйт**

| | берлек | күплек |
|---|---|---|
| **I зат** | / | / |
| **II зат** | / | / |
| **III зат** | / | / |

## әйт

| | берлек | күплек |
|---|---|---|
| I зат | әйткәнмен / әйтмәгәнмен | әйткәнбез / әймәгәнбез |
| II зат | әйткәнсең / әйтмәгәнсең | әйткәнсез / әйтмәгәнсез |
| III зат | әйткән / әйтмәгән | әйткәннәр / әйтмәгәннәр |

*Үткән заман фигыльләренең бер төреннән икенче төрен ясагыз.*

**“Бер якта аллы-гөлле, кызыллы-яшелле чүпрәк диңгезе үз алдында дулкынланып тора – болар хатын-кызлар. Икенче якта, бик куе булып, ирләр бер түгәрәк ясап оешканнар. Монда көрәш барадыр. Болардан читтә бала-чага, карт-коры, сатучы-фәлән, ат, арба, белмим, әллә ниләр кара болыт кебек бөтен сыртны каплап алганнар.”**



# Фигыльнең заман белән төрләнеше

| № | фигыль | хәзерге заман | билгеле үткән заман | билгесез үткән заман | билгеле киләчәк заман | билгесез киләчәк заман |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | уят | уята | уятты | уяткан | уятачак | уятыр |
| 2 | көт | көтә | көтте | көткән | көтәчәк | көтәр |
| 3 | сакла | саклый | саклады | саклаган | саклаячак | саклар |
| 4 | сөйлә | сөйли | сөйләде | сөйләгән | сөйләячәк | сөйләр |

# Фигыльнең зат-сан белән төрләнеше

| № | хәзерге заман | билгеле үткән заман | билгесез үткән заман | билгеле киләчәк заман | билгесез киләчәк заман |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | ябам | яптым | япканмын | ябачакмын | ябырмын |
| 2 | көләсең | көлдең | көлгәнсең | көләчәксең | көләрсең |
| 3 | саный | санады | санаган | санаячак | санар |
| 1 | булабыз | булдык | булганбыз | булачакбыз | булырбыз |
| 2 | ачасыз | ачтыгыз | ачкансыз | ачачаксыз | ачарсыз |
| 3 | көйлиләр | көйләделәр | көйләгәннәр | көйләячәклә р | көйләрләр |

# Фигыльнең барлык-юклык белән төрләнеше

| № | хәзерге заман | билгеле үткән заман | билгесез үткән заман | билгеле киләчәк заман | билгесез киләчәк заман |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | утырмыйм | утырмадым | утырмаганмын | утырмаячакмын | утырмамын |
| 2 | килмисең | килмәдең | килмәгәнсең | килмәячәксең | килмәссең |
| 3 | бәйләми | бәйләмәде | бәйләмәгән | бәйләмәячкк | бәйләмәс |
| 1 | күрмибез | күрмәдек | күрмәгәнбез | күрмәячәкбез | күрмәбез |
| 2 | ятмыйсыз | ятмадыгыз | ятмагансыз | ятмаячаксыз | ятмассыз |
| 3 | йөрмиләр | йөрмәделәр | йөрмәгәннәр | йөрмәячәкләр | йөрмәсләр |

# Йомгаклау

***Өзекләрдән төрле заман фигыльләрен табып әйтеп чыгыгыз.***

**“Теге данлыклы Күк бия дә килеп җитте. Курүгә шуңардан күземне алмадым. Гаҗәп бер мал икән: кыска яллы, сирәк койрыклы, чандыр гәүдәле нәрсә. Очасы тар, бер якка бераз чалыш, аркасы бераз бөкерерәк. Әмма күкрәк дигәне бөтенләй арысланныкы – шундый киң, шундый нык күренә. Тезләре ике яккарак китеп тора, бәкәлләренә карагач, тагы хәйран калдым; алар шундый озыннар ки, мин гомеремдә андыйны күргәнем юк. Күзләре зурлар – уйнап, ялкынланып торалар. Өстенә кечкенә, кап-кра, башы бөтенләй ялангач, кулына камчы тотып, бер башкорт малае менгән.”**

**“Алмачуар җан биргәндә мин аның баш очында идем. Епый алмадым. Йөрәгем таш булып катты.**
**Шуннан соң, дөньяда һичбер малга, һичбер әйбергә күңелем дә, күзем дә төшмәде: һичбер нәрсәне сөя алмадым.**
**Алмачуар минем йөрәгемдә: җиргә, күккә, адәмнәргә, бөтен нәрсәләргә булган мәхәббәтемне үзе белән бергә алып китте.”**